МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ДОМ ДЕТСКОГО И ЮНОШЕСКОГО ТУРИЗМА И ЭКСКУРСИЙ
МОСКОВСКОГО РАЙОНА ГОРОДА КАЗАНИ

# Методические материалы
# в помощь педагогам дополнительного образования детей
# по программе «Яшь экскурсоводчы»

Автор:
Педагог дополнительного образования
Гатауллина Зульфия Ильдусовна

Казань 2022г

## Экскурсия

***Казанның рус өлешеннән татар өлешенә***

## Куелган максатлар:

1. Кунакларны Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары белән таныштыру.
2. Казанның ике өлеше белән таныштыру.

Экскурсия вакыты – 2 сәг.

**Экскурсиянең методик кулланмасы**

| Маршрут | Тукталыш | Объектны күрсәтү | Күрсәтү вакыты | Төп темасы |
|---|---|---|---|---|
| Казан Кремле-Иске -Татар бистәсе | 1.Казан Кремле | Казан Кремле янында | 10- мин | Кыскача Казан Кремле турында сөйләү |
| | 2. Кремль урамы буйлап | Кремль урамындагы биналар | 15-20 мин | Биналар:<br>1)Александров пассажы<br>2)Чернояров пассажы<br>3)Ушакова йорты |
| | 3.Казан дәүләт университеты | Кремль урамы | 10мин | КДУ турында кыскача гына сөйләү |
| | 4.Профсозлар һәм Бауман урамны кисешкән урыны | Профсозлар һәм Бауман урамны кисешкән урыны | 15 мин | Бауман урамы тарихы турында сөйләү |
| | 5. Татарстан урамы | Татарстан урамы | 20 мин | 1.Болак панорамасы<br>2. Г.Камал театры<br>3. Кабан күле |
| | 6.Иске-Татар бистәсе | Иске-Татар бистәсе | 40мин | 1.Солтан мәчете |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | буйлап | | 2.Мөхәммәдия мәдрәсәсе<br>3.Укытучылар мәктәбе<br>4. Мәрҗани мәчете |

1.Кереш өлеше.

Исәнмесез, хөрмәтле кунакларыбыз. Мин сезне күпмилләтле Татарстан башкаласы булган Казан шәһәрендә сәләмлим. Һәркемгә дә үз туган ягы бик кадерле. Кеше кая гына барса да, барыбер күңеле белән үзенең газиз туган авылына, туган шәһәренә ашкынып кайта.

Безнең чиксез киң илебездә матур шәһәрләр һәм авыллар бик күп. Тик бөек татар телендә аңлашып, сөйләшеп, татар халкының гореф-гадәтләренә буйсынып яшәгән кешеләр, әлбәттә, Татарстан республикасында гомер кичерә.

Казан – Татарстан республикасының башкаласы, Русиянең икътисади, мәдәни, сәяси үзәкләренең берсе. Иделнең сул ягында, аңа Казансу кушылу урынында урнашкан зур порт.

Шәһәрнең теркәлгән «Русиянең өченче башкаласы» дип йөртәләр.2005 елда Казан шәһәре 1000-еллыгын бәйрәм итте, 2013 елда Казанда XXVII Җәйге Универсиада узды. 2015 елда — су спорт төрләре буенча Дөнья чемпионаты үткәрелде, ә 2018 елда шәһәр (Русиянең башка шәһәрләр белән) ФИФА Дөнья футбол чемпионатын кабул итә.

Шулай ук хәзерге Татарстан йөздән артык милләткә туган йорт, туган як. Ул күп милләтле республика. Мең еллык тарихы булган, бөтен дөньга танылган шәһәр. Республикабызның башкаласы булган Казан − Идел буендагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Әйе, данлы, борынгы шәһәр. Аңа 1000 ел элек нигез салынган. Бүгенге көндә Казан − миллионнан артык халкы булган зур шәһәр. Ул истәлекле урыннарга бик бай.

Безнең шәһәребез елдан – ел үсә,матурая: гүзәл сарайлар, биек йортлар барлыкка килде. Казанның берсеннән-берсе матур йортлары, урамнары, истәлекле биналары турында сез ниләр беләсез?

Әйдәгез, Казан буйлап сәяхәткә чыгабыз. Экскурсоводыгыз, мин 8К сыйныф укучысы Шәмсетдинова Диләрә, булам. Кузгалдык!

2. Төп әлеше

Безнең экскурсиябез Казанның элек рус өлеше дигән җирдән башлана. Безнең экскурсиябез Кремль янышнан башлана.

Казан Кремле турында 16 гасырда ук тарихчылар бик сокланып язганнар. Аның эчендә таштан эшләнгән хан сарайлары һәм мәчетләре булган. Хан сарае хәзерге ТР Президенты резеденциясе урынында булган. Сарай каршындагы зур мәйданда биек каравыл манарасы торган.

Кремльгә кергәндә,  ап-ак Спас манарасы урнашкан. Ул 16нчы гасырда төзелгән, 18нче гасырда аңа сәгать урнаштырылган.

Казан Кремле белән университетның төп бинасын Кремль урамы тоташтыра. Революциягә кадәр бу урам – Воскресенская, соңрак Ленин исемен йөрткән. Бу урамда 19 гасыр ахыры- 20 гасыр башында төзелгән биналар, сәүдә йортлары, төрле кибетләр урнашкан.

Хәзер без Кремль урамы буйлап төшербез.  Кремль урамы — Казанның Вахитов районында урнашкан үзәк урам. 1 нче Май мәйданыннан башланып КФУның Университет бакчасына кадәр дәвам итә.Элек Спасс урамы, Воскресение урамы (XVII гасыр ахырыннан), Чернышевский урамы (1917 елдан), Ленин урамы (1960 елдан) дигән исемнәрне йөрткән. 1990 елларда урамга Сөембикә исемен бирергә тәкъдим ителсә дә, 1996 елда аңа хәзерге исеме бирелә. Урам XVI гасырда барлыкка килә. Күпләп биналар биредә XIX гасырда төзелә башлый. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында урамда трамвай юлы узган.

Урам башында 18нче гасырның административ биналары, бераз узгач, сезгә ике бик матур пассаж күренер. Бу- Александров һәм Чернояров пассажлар.

Александров пассажы — Казан үзәгендә урнашкан эре бина, шәһәрнең истәлекле урыннарының берсе.1880—1883 елларда төзелгән. Бинаны сәүдәгәр Александр Александров заказы буенча[1] В. В. Суслов һәм Н. И. Поздеев проекты буенча Петербург мигъмары Генрих Руш төзегән.

Иң башта пассаж Воскресение, Петропавловел, Почтамт урамнары һәм Черек күл бульвары белән чикләнгән кварталны биләп торган; соңрак Почтамт һәм Воскресение урамнары чатына чыгучы пассаж өлеше югалтылган.

План буенча, пассаж табышлы урын булырга тиеш булган, әмма ул хуҗасына зыян генә китергән. Шуңа күрә ул йортны үз апасына — генерал хатынына Ольга Александрова-Гейнцка саткан; ул исә йортны шәһәренә музей урнаштыру өчен бүләк итте. Бу типтагы бинаны музей өчен яраксыз дип тапканнар, Пассаж табышлы йорты булып та калган. Пассаж эчендәге урннарны кибетләр, һөнәрханәләр, конторалар арендага алганнар.

Бөек Ватан сугышы вакытында биредә эвакуацияләнгәннәр, яшәгәннәр.

1977 елда бинаның өлеше ишелеп төшкән.

Совет дәверенең азагына бина авариячелгә якын хәлдә калган. Әлеге вакытта бина яңартып төзелештә тора. 2018 елгача биредә бишьйолдызлы кунакханә ачылырга тиеш.[2]

Чернояров пассажы — Казан үзәгендә урнашкан эре бина, шәһәрнең истәлекле урыннарының берсе. 1901 елда төзелгән. Русия империясе дәверендә Казан Мәскәү белән Петербургтан кала бердәнбер ике пассажлы шәһәр булып торган. Бина 1901 елда сәүдәгәр А. П. Чернояровның табышлы йорты буларак төзелгән. Ул XIX гасырның азагы — XX гасыр

башы эклектик формаларында төзелгән һәм беренче катта сәүдә зонасы булган табышлы йортының үрнәге булып тора.

Икенче һәм өченче катлар үзәк баскыч келәткәле коридор планлаштыруга ия булалар; бинаның ишегалдында баш бинасы белән түбәсе ябылган кичүләр аша тоташтырылган өстәмә торак корпуслары бар. Ишегалдындагы флигель баш бинасы белән стилистик берлектә ясалган; ул, мөгаен, хуҗалар тораган урыны булып торгандыр.

Сәүдә итү үзәге сыйфатын пассаж Октябрь инкыйлабына гына башкарган, аннан соң 2—3 катларны торак өчен үзгәртеп ясаганнар.

Әлеге вакытта бинада офислар, кибетләр урнашканнар. Экскурсиябезне дәвам итәбез.Кремл урамы, 33 нче йорт.

Ушкова йорты — Казанда урнашкан бина, XX гасырның башында эклектик стилендә үзгәртеп төзелгән. Әлеге вакытта биредә Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе урнашкан.

Ушкова йорты — ике катлы, штукатурлаган кирпеч бина, тәмам булмаган каре формасын хәтерләтә, бинаның алъягында зур булмаган яссы ризалитлар бар.

Казан университетының табигый факультетында укыган чакта, Алексей Ушков — миллионер Константин Ушков улы — Зинаида Высоцкаяга (хирургик патология профессоры кызы) өйләнгән. Ушков йорты 1904—1908нче елларда Воскресение урамында урнашкан өч йорттан үзгәртеп төзелгән.

1919нче елдан Ушкова йорты Үзәк китапханәсенең баш бинасы булган (1923 елдан — В. И. Ленин ис. Үзәк шәһәр китапханәсе, 1934 елдан — В. И. Ленин ис. Өлкә китапханәсе, 1941 елдан — В. И. Ленин ис. Җөмһүрият китапханәсе, 1991 елда — Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе) — Идел буеның иң зур китапханәләренең берсе.

Ун ягында Казвн университеты. Казан (Идел буе) федераль университеты, КФУ— Казан шәһәренең югары уку йорты. Русиянең иң борынгы университетларының берсе. 1925нче елдан 2009 нче елга кадәр В. И. Ленинның исемен йөртә. 2009 нчы елның 21 октябрендә Русия президенты указы буенча Казан Дәүләт Университеты нигезендә — Казан (Идел буе) федераль университеты оештырыла.

КФУ эченә Казан дәүләт финанс һәм икътисад институты, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм ТР Президенты буендагы дәүләт һәм муниципаль хезмәте академиясе кертелә. Реорганизация нәтиҗәсендә, элекке КДУның факультетларының бәгъзеләре институт статусын ала. Русия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектлары җыентыгына кертелгән. Университет, Астрономия, Лобачевский һәм Профессор Нужин урамнары арасындагы кварталын биләп торучы Казан университетының мигъмари ансамбле Русиянең тарихи-мәдәни, шәһәр төзү һәм мигъмари һәйкәле, Казанның истәлекле урыны булып санала.

Университетның төп уку биналары комплексы, ягъни университет шәһәрчеге, Казанның Вахитов районында, шәһәрнең үзәк өлешендә, Казан

Кирмәненнәнбер километрда, Тукай мәйданы метро станциясеннән ярым километрда урнашкан.

Университет – Татарстанның горурлыгы. Аңа 1804нче елда нигез салына. Унивеситетта атаклы математик Н.Лобачевский,органик кушылмалар теориясенә нигез салучы А.Бутлеров, атаклы табиблар П.Лесгафт һәм В.Бехтерев, тел галимнәре И.Хәлфин, Н.Катанов һәм башкалар эшләгәннәр. Бу югары уку йорты Идел буе халыкларының мәдәният һәм мәгариф үсешенә зур йогынты ясаган. Казан университеты- бүгенге көндә дә Россиядә иң данлыклы уку йортларының берсе. Бу бина 1822-1825 нче елларда төзелгән. Архитекторы- П.Г.Пятницкий.

Университетның борынгы ак таш бинасы янында өч мәһабәт бина бар – аларда булачак физиклар, математиклар, химиклар, филолаглар, журналистлар, тарихчылар гыйлем серләрен ачалар.

Хәзерге университет ул – заманча җиһазландырылган аудиторияләр, лабораторияләр, обсерваторияләр, тәҗрибә станцияләр, спорт комплексы, бай фондка ия китапханә, берсннән-берсе кызыклы коллекциләр тупланган зоология, геология, этнография музейлары.

Республикабызның Милли китапханәсе дә, университет архитектурасына ярашып, аңа матурлык өсти. Шәһәрнең иң матур корылмаларыннан санала ул. Аның яныннан битараф узып китеп булмый. Бу бинаны 19 нчы гасыр башында фабрикант Ушаков салдырган, соңыннан ул китап йортына әверелгән.

Бу нисбәттән әтиле-уллы Второвлар турында кызыклы истәлекләр сөйлиләр. Заманның шактый зыялы кешесе И.А.Второв гомере буе китап җыйган. Аның китапханәсендә төрле телләрдәге китаплар тупланган. Байлык мирас булып, улы Николай Второвка күчкән. Петербургка күчеп киткәндә, ул этисе китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк иткән. Шулай итеп, 1865 нче елда Казанда китапханәсе ачылган.

Арыслан, аждаһа, төрле кошлар сурәләре, борынгы баскычлар. Унда да, сулда да, каршыда да – ишекләр, катологлар, киштәләр. Ишекләрнең берсе – борынгы кульязмалар, икенчесе сирәк китаплар бүлегенә алып керә. Калганнары татар китаплары, туган якны өйрәнүгә багышланган басмалар бүлегенә чакыра.

Дөнь әдәбияты, сәнгать бүлеге, фәнни әдәбият, техник әдәбият, библиография, фәнни-методик әдәбият бүлекләре. Газета-журналлар өчен- аерым бүлмәләр. Бу йорт 3 млннан артык китапны сыйдыра.

Белеп торыгыз: биредә беркайчан да “китап юк” димиләр. Үзендә юк икән, бөтен Татарстаннан эзлиләр. Анда да булмаса, Россия Дәүләт китапханәсенә яки С-Петербургның Үзәк китапханәсенә мәрәҗәгать итәләр. Юк икән, чит илгә чыгалар. Америкага, Төркиягә, Германиягә, Финляндиягә. Милли китапханә 83 илнең китапханәләре белән килүшеләр төзегән. Иң тыгыз элемтәләр Америкадагы Конгресс китапханәсе белән урнаштырылган.

Тарихка тукталыйк. Татарстанның баш китапханәсе 1991 нче елда Милли китапханә статусын алды. Казан җәмәгать китапханәсенең Мөселман

бүлеге 1906нчы елда ачыла. Аны оештыручыларның берсе галим һәм мәгърифәтче Әхмәтһади Максуди була. Фондта 915 исемдәге 1277 китап саклана.

Кульъязмалар һәм сирәк китаплар фондында татар, гарәп, фарсы, төрек, рус һәм башка телләрдәге китаплар, кульъязма һәм фотоматериаллар, революциягә кадәр чыккан татар газеталарының төпләмнәре тупланган. Китапханәдә тарихка караган тикшеренүләр, миниатюр басмалар, бер генә нәсхәдә калган китаплар саклана.

Китапханәнең эшчәнлеге күпкырлы. Анда фәнни-гамәли конференцияләр, яхзучылар белән очрашулар уздырыла, артистлар чыгыш ясый. Ел саен иң популяр китап конкусына йомгак ясала. Күргәзмәләр оештырыла, китапка багышланган әдәби кичәләр үткәрелә.

Ә хәзер без сезнең белән аска төшәбез, Профсоюзлар һәм Бауман урамы кисешкән урында тукталып калырбыз. Бу урамнарның тарихы бик кызык. Барганда тыңлап калагыз.

Профсоюзлар урамы - Казанның тарихи үзәгендә урнашкан урам. Бауман урамы белән киселешеннән башланып, Пушкин урамы белән киселешен дә тәмамлана. Чернышевский, Муса Җәлил, Кави Нәҗми һәм Астрономия урамнары белән кисешә. Элек Кече тишек урамы (рус. Малая Проломная) дип аталган. Хәзерге исемен 1929нчы елның 16 маеннан йөртә.

Бауман урамы — Казанның Вахитов районында, тарихи үзәктә урнашкан урам. Бауман урамы Казанда иң борынгы урамнарның берсе. Ул Казан ханлыгы чорында ук булган (шул вакытта ул Ногай юлы атамасын йөрткән). Әлеге вакытта 1905нче елда Мәскәүдә үтерелгән инкыйлабчы Николай Бауман хөрмәтенә атала.

Бауман урамы – Казан үзәгендә урнашкан җәяүле урам. Төрле елларда ул Ногай улы, Проломная, Зур Проломная, дип йөртелә. Элек Бауман урамында трамвайлар, троллейбуслар, автобуслар да йөргән. Бүген җәүлеләр генә йөри торган урамның баш-башында Тукай скверы һәм «Кремль» метро станцияләре урнашкан.

Һәр шәһәрнең үзәк урамы бар. Ул административ, мәдәният, сәүдә оешмаларының күплеге белән башкалардан аерылып тора. Казанның Бауман урамына да шул ук сыйфатлар хас. Әлеге урамга Бауман исеме 1930 елны бирелә. Аңа кадәр урам Большая Проломная дип йөртелә. Беренче карашка бик гади генә күренсә дә, бу исем дә тарихи. 1552 елда Явыз Иван гаскәрләренең Казанга һөҗүме вакытында Кремль стенасын шартлаталар. Нәтиҗәдә зур тишек барлыкка килә. Шуны халык хәтерендә калдыру максатыннан, урам Большая Проломная (Зур Тишек) дип йөртелә башлый. XVI гасырның 60 нчы елларында урам бүгенгедәй озын булмый әле. Кремль яныннан башланып, бүгенге Качалов театры тирәсендә тәмамлана. Урамның уң ягында (Болак ягында) – ун, сул якта ундүрт йорт булуы мәгълүм. Бауман урамын бүген дә киң дип булмый, ул чорда урам тагын да таррак булган. XVI гасырда урамның көньяк өлешендә яңа бистә барлыкка килә. Бу урамда чиркәү төзелгәч, аны Богоявленский бистәсе дип йөртә башлаганнар.

Ул чорда ук Большая Проломная урамы шәһәрнең сәүдә үзәге буларак хезмәт итә. Арзанлы су юлы Болак буйлап товарлар китерелә. XVIII гасыр ахырына урам формалашып бетә, әкренләп, шәһәрнең иң зур урамнарының берсенә әверелә. Революциягә кадәр үк урамга таш җәелә. 1987 елдан Бауман

урамында транспорт хәрәкәте туктатыла.

Тагын алга барабыз, Болак ярына килеп җитәбез. Элек бу урынны Казанның татар өлеше дип йөрткәннәр.

Сәяхәтебезне дәвам итәбез. Пушкин урамыннан үтеп, Татарстан урамына чыгабыз. Ун якта Г.Камал исемендәге дәүләт академия театры. Ул 1986нчы елда архитекторлар М.Х Агишев һәм М.Н.Горлышев проектлары буенча төзелгән. Сул якта Болак панорамасы, ә ун якка карасагыз – Кабан күле. Иске бистә, Иске Татар бистәсе (рус. Старо-Татарская слобода) — Казан шәһәренең Вахитов районының көньягында урнашкан тарихи бистә. Бистәнең үзәк урамы булып Тукай урамы тора.

Үзенең барлыкка килү тарихы белән Казанның Иске Татар бистәсе XIV-XVI гасырларга карый. Тулысынча ул XIX гасырда гына оешып бетә.

Гомумән, шәһәребезнең Иске Татар бистәсе Казан халкының гына түгел, ә дөньяның төрле почмакларыннан килгән туристларның да яраткан урынына әверелде.

Әлеге бистәнең тарихына күз салсак: Явыз Иван Казанны яулап алганнан соң мөселманнарны шәһәр читенә куып чыгаралар. Шәһәр читендә, Болак артында татарлар районы формалаша һәм вакытлар узгач, Иске Татар бистәсе дип атала башлый. Берничә гасыр буена монда татар халкының гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен сакланып килгән һәм үсешен дәвам иткән.

Татарларның урыс патшасы белән уртак тел таба алган аз өлеше генә Казаннан ерак түгел Түбән Кабан күле һәм Болак каналыннан көнбатыштарак урнаша алган. 1767нче елда Казанга патшабикә Екатерина II килгән. Мөселман мәхәлләсе вәкилләре белән очрашуда, татарларның кунакчыллыгыннан һәм бүләкләреннән кәнәгать булып, бистәдә таштан ике ак мәчет салырга рөхсәт биргән. 1773нче елда «Диннәрнең тигезлеге хакында» указ кабул ителгән һәм беренче тапкыр, берникадәр чикләүләр белән булса да, дин тоту иреге бирелгән. Шул вакыттан башлап бистә Казанның мәдәни һәм дини үзәгенә әйләнә.

XIX гасыр уртасына бистәнең өч тарихи өлеше барлыкка килгән: төньягында – сәүдә, үзәктә - мәдәният-торак һәм көньягында – сәнәгать. Бистәнең төньягында, үзәктә, кунакханәләр һәм сәүдә биналары урнашкан. Печән базары мәйданы һәм мәчет булган, хәзерге вакытта ул Нурулла мәчете дип атала. Бистәнең үзәге Юнысов мәйданы булган.

Иске Татар бистәсендә сакланып калган XVIII-XIX гасыр биналары арасында барокко, классицизм һәм эклектика стилендәгеләре бар. Бистәдәге корылмаларның аерым бер үзенчәлеге - рус һәм татар архитектурасы гореф-гадәтләренең кушылуы.

Бистә тарихында күп кенә татар морзалары һәм сәүдәгәрләренең исемнәре саклана. Бик күп татар гаиләләре үзләреннән соң бай тарихи

мирас калдырганнар: затлы, матур йортларга карап моннан берничә гасыр элек татар зыялыларының тормыш рәвешен күз алдына китерергә мөмкин. Мәсәлән: Юнысов-Апанаевлар йорты, Мәрҗәни, Сабитов, Исәнбаевларның йортлары.

Шулай ук бистәдә сәүдәгәрләрнең акчаларына һәм имамнар тырышлыгы белән салынган тарихи мәчетләрне дә күреп була. Халык бу мәчетләргә салдыручыларның исемнәре белән атап йөрткән: Әҗем, Апанай, Галиев мәчетләре...

Бистәнең барлыкка килүе турында истә төрле риваятьләр йөри. Аларның берсенә күрә, Казанны яулап алгач, Иван патша шәһәрнең исән калган татарларына: «Вот вам место» дип, Кабан артындагы сазлыклы җирләргә күрсәткән. Әмма мондый сүзләр дөрес түгел, ди тарих фәннәре кандидаты Рәшит Галләмов.

Казан ханлыгы чорында ук, хәзерге Татарстан урамыннан башлап, аннан көнбатыштарак, Үзәк базар тирәләрендә Корәеш бистәсе булуы мәгълүм, ди ул. Бу бистә рус кулъязмаларында «Слобода Кураешова» исеме белән Казанның 1565-1568нче еллар халык санын теркәү кенәгәсендә искә алына.

Бистәдә барлыгы 9 мәхәллә булган, аларның һәрберсенә мәчет, мәдрәсә, мулла йорты һәм мәчет белән мәдрәсәне тәэмин итеп торучы эшмәкәрләр һәм хәйриячеләр йортлары кергән.

Сәяхәтемне Иске татар бистәсе белән таныштырудан дәвам итәбез.

Казанны руслар яулап алганнан соң, исән калган татар халкы шәһәрдән урманнарга, авылларга һәм хәтта Урал якларына качкан. Ә кайберләре Казанның көньяк читендәге кеше керә алмаслык камышлы сазлыкларда яшеренгәннәр.Ул сазлыклар Идел буе болыннарына хәтле җәелгән була.

Дошманнар кул астында калган шәһәр халкының бер өлеше Болак суы белән Кабан күле аръягына куылган. Бу тирәләр соңыннан Иске Бистә дип аталган. Ул бистә күп тапкыр янган. 1749нчы елгы янгыннан соң татарларны Иделдән өч чакрым чамасында булган, югарыда телгә алынган сазлыклы җирләргә күчәргә мәҗбүр иткәннәр. Өч йөзләп кеше башлап күченгән урынга Яңа бистә исеме бирелгән.

Иске һәм Яңа бистәнең кушылган чикләрен билгеләү хәзер кыен. Иске Бистәгә Болакның сул ягы һәм Акком астыннан Вахитов мәйданына чаклы Кабан күле буе кергән. Иске татар бистәсенең үзәге ике урам була: Екатерина һәм Тихвин. (Шул урамнардагы чиркәүләр исеме белән аталган.) Тихвин урамы Зур Варлаам урамына кушылып китә.Хәзер бу урында Колхоз базары.

Монда сәүдәгәрләр һәм дин әһелләре күчеп килә.Төзелештә татар стиле өстенлек итә. Хәзер бу урам татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай исемен йөртә. Монда бөтенесе Тукай исеме белән бәйләнгән. 63 нче йортта 1907-1909нчы елларда Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан катнашы белән "Әльислах" газетасы бастырып чыгала. 1907нче елның 10 октябрендә Уральскидан Казанга кайтканнан соң, Тукай яшәгән Болгар номерлары(1907-1912) бу урамга бик якын урнашкан. Тукай урамы бик озын. Анда 130лап йорт бар.

Урам башына такта куелган: “Бу урам татар халык шагыйре Габдулла Тукай истәлегенә багышлап исемләнә”. Тукай урамының һәр йортының үз кызыклы тарихы бар. Шуларның кайберләренә тукталып китим әле. Иң беренче булып күз алдыбызга “Солтан” мәчете күренә. Ул 19нчы йөз ахырында төзелгән. Монда сезнең белән тукталыйк.

Солтан мәчете. Аның элекеге исемнәре: Җиһанша бай мәчете, Кызыл мәчет, Госман мәчете, Сигезенче җәмигать мәчете. Ул Казанда татар дини архитектура истәлеге. 1868нче елда сәүдәгәр Җиһанша Госманов истәлегенә төзелә. Ул урта гасыр болгар үзенчәлекләре белән милли романтик юнәлештәге эклектик формаларын үзенә ала. Мәчетнең архитекторы-П.Е.Аникин. Бер заллы, ишек өстендә өч катлы манаралы, антресольле җәмигъ мәчет. 1856нчы елгы янгыннан соң, Җиһанша бай хәзерге Колхоз базары тирәсе җирләрен мөселманнар өчен урынын сатып ала. Бу урында ул мәчет, мәдрәсә, имам йорты һәм мәхәллә салдырасы килә. Җиһанша байдан соң мәчетне аның ике туганы Таһир һәм Мөхәммәтшакир Госмановлар карап торганнар.

19нчы йөзнең 90нчы елларыннан бу эшне Җиһанша бай улы Солтангабделгазиз (1868 – 1917) үз өстенә ала. Мәчет тә аның исеме - Солтан мәчете дип атала. 1931нче елдан ул ябыла. Манарасы бары тик 1990нчы елда торгызыла. Ә 1994нче елдан яңадан ачыла һәм үз вазифасын үти башлый.

Алга таба тагын бер дини уку йорты янында тукталабыз. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе. Ул Тукай урамындагы 34 нче йортта урнашкан. Ул 1882нче елда Казанда ачыла. Галимҗан Баруди аңа нигез сала һәманың белән җитәкчелек итә. 1882нче елда аның атасы Йосыф Сәгыйтов, мәдрәсәсе ишегалдындагы бер катлы таш бина төзелешенә акча бирә. Мәдрәсә биналарын киңәйтү өчен XX гасырның урталарына кадәр дәвам ителә. Нигез салучы Мөхәммәтҗан хөрмәтенә “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе дип атала башлый.

1882 – 1918нче елларда меңнән артык укучылар башлангыч һәм урта белем ала. Алар арасында татар халкының атаклы шәхесләре: Х.Ямашев, Ф.Әмирхан, Ф.Бурнаш, М.Гафури, Н.Исәнбәт, Галиәсгар, Габдулла, Габдрахман һәм Әнәс Камаллар, С.Сәйдәшев, К.Тинчурин, С.Габәши, Б.Урманче, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин һ.б. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе биналары комплексы – татар архитектурасы истәлеге. 1883 – 86нчы елларда М.Галиев, Ә.Сәйдәшев, Г.Үтәмишев кебек сәүдәгәрләр акчасына өч катлы бер бина корыла, ә 1901нче елда сәүдәгәрләр Ә.Хөсәенов, Г.Үтәмишев һ.б. акчасына эклектика стилендәге өч катлы янкорма төзелә.

“Мөхәммәдия” мәдрәсәсе 1882нче елдан башлап 1918нче елга кадәр эшләп килгән. Шул вакыт эчендә мәдрәсәдән мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш керткән җәмәгать эшлеклеләре, мәгърифәтчеләребез тәрбияләп чыгарыла. Мәдрәсә белән күренекле галим Галимҗан Баруди җитәкчелек итә. ”Мөхәммәдия” мәдрәсәсе ул вакытта югары белем бирүче уку йорты булып тора.

Тик 1993нче елда беренче студентлар “Мөхәммәдия” институты бусагасын атлап керәләр. “Мөхәммәдия” Ислам институты – дини белгечләрен әзерләүче уку йорты. Анда югары дини белем бирәләр.

Хәзерге вакытта көндезге бүлектә 500 гә якын укучы укый. 1997нче елда Г.Тукай урамында урнашкан “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе бинасы хуҗаларына кайтарылып бирелә.

“Мөхәммәдия” мәдрәсәсе динебез турында кайгыртучы милләттәшләребезнең ярдәме хисабына эшләп килә.

Әйтмичә булмый - Тукай урамының 73 нче йортында урнашкан Укытучылар мәктәбе турында. Бу татарлар өчен рус телендә белем бирү мәктәбе. Ул 1876нчы елның сентябрендә ачылган. Монда 10 укучы була. Мәктәптә 4 сыйныф кына булган. Татар мәктәбе 3 катлы йортта урнашкан була. Анда физика, тарих кабинетлары, химия лабораториясе, физик күнегүләр ясау өчен төрле снарядлар була. Петербургтан китапханә өчен төрле китаплар, карталар, глобуслар алып кайтарталар. Шулай ук Германиядән кабинетлар өчен төрле кирәк - ярак,телескоп, кулланма һәм күрсәтмә материаллар – барысы 3 мең сумлык әйберләр кайтартыла.

Татар укытучылар мәктәбенең беренче инспекторы А.Мәхмүтов булган. Аңа кадәр ул 27 ел Казан университетында эшләгән. Дин белемен монда Ш.Мәрҗәни укыткан. Соңрак укытучылар булып, шушы мәктәпне тәмамлаучы укучыларны калдыралар. 1876нчы елдан 1884нче елга кадәр бу мәктәпнең җитәкчесе В.Радлов була.Монда шулай ук танылган тел белгече В.Богородский, татар мәгърифәтчеләре К.Насыйри һәм И.Терегуловлар эшли.

Экскурсиябезне дәвам итәбез. Безнең каршыбызда Борнай мәчете. Ул Казандагы татар дини архитектурасы истәлеге. Г.Тукай һәм Әхтәмов урамнары киселешендә урнашкан. 1872нче елда сәүдәгәр И.К.Борнаев иганәсенә архитектор П.И.Романов проекты белән милли романтик юнәлештәге электика формаларында төзелә. Манарасы 1895нче елда архитектор Ф.Н.Малиновский проекты белән куела. Ишек өстенә утыртылган манаралы, бер заллы, бер катлы кирпеч бинадан мәчет.Эчке яктан өчкә бүленгән: керү өлеше, вестибюль,намаз уку өлеше.Тышкы ягын бизәүдә урта гасыр татар һәм рус архитектурасы элементлары кулланылган. 1930елда ябыла. Тик 1994нче елдан үз вазыйфасын башкара башлый

Сәяхәтебезне иң борынгы мәчет янында тәмамлыйбыз. Мәрҗани мәчете – элек ул Беренче җәмигъ, Әфәнде, Юныс мәчете дип аталган.1552нче елдан соң төзелгән тәүге таш мәчетләренең берсе. Екатаерина патшаның шәхси рөхсәте белән 1766–1770нче елларда дини кешеләре акчасына салына. Проект авторы - В.И. Кафтырев булырга мөмкин. 1861нче елда коммерция советнигы Ибраһим Гобәйдулла улы Юнысов (1806–1886) тырышлыгы белән мәчет төзелә башлый. 1863нче елда шул ук сәүдәгәр мәчетнең михраб урынын киңәйтә, зурайта, шунда тәрәзә дә ясата. 1885нче елда икенче гильдияле казан сәүдәгәре Зәйнулла Госманов мәчет манарасын яңадан, үзгәртеп төзеп куя. 1887нче елда сәүдәгәрләр Вәлиулла

Гыйззәтуллин (1837–1916) һәм Мифтахетдин Вәлишин (1811–1904) акчасына мәчет манарасының түгәрәк балконы челтәрләп эшләнгән тимер парапет (култыкса сыман җайланма) белән әйләндереп куела.

1850–1889нчы елларда мәчеттә имам-хатыйб булып күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог, дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани эшли. Аның бинасы ике катлы. Мәчетнең беренче каты төрле хуҗалык эшләре (ихтыяҗлары) өчен көйләнгән, икенчедә уку заллары урнашкан. Мәчетнең эчке биналары гөмбәзле түшәм белән капланган. Икенче кат гөмбәзләре алтын йөгертелгән үсемлекләр орнаменты һәм әвәләп ясау сәнгате үрнәкләре белән бизәлгән. Аларда барокко декоры белән татар декоратив-кулланма сәнгате алымнары күренә. Диварларда ясалган бизәкләр зәңгәр, яшел һәм алтын төсләргә буялган. Манара эчендәге бормалы баскыч өске яруска алып бара, шуннан түгәрәк балконга чыгарга мөмкин. Манара ярусларының өчесендә дә декоры юк ,чөнки алар эклектизм чорында төзелгән. Икенче каттагы тәрәзәләре барокко стилендә эшләнгән. Мәрҗани мәчете — XVIII–XIX гасыр дәвамындагы татар-мөселман архитектурасының иң гүзәл истәлекләренең берсе. Мәрҗани мәчете – ул татар-мөселман традицион монументаль архитектурасы яңадан торгызу, аякка басу. Мәчетнең тышкы һәм эчке өлешләрендә — барокко мотивлары кертелә. Ул замана өчен мәчет алдынгы архитектура стиле белән архитектурасы белән- күренекле, үзенчәлекле урын ала.

Хәзер сез мәчеткә керә аласыз.

3.Төгәлләү

Иске-Татар бистәсендәге мәчетләр, биналар, йортлар Казанның иң истәлекле , тарихи урыннары. Бу урынны изге урын дип ата алабыз., чөнки монда чын татар кешесенең рухы яши, тормышыбызга ямь бирә. Киләчәк буыннарга да бу тарихи урыннарны онытырга ярамый дип уйлыйм.

Ә без сезнең белән саубуллашабыз. Сезгә яхшы еллар һәм киләсе очрашуларга кадәр. Саубулыгыз.

# Кулланылган әдәбият


1. Айдаров С.С. Казань в памятниках истории и культуры.-Казань, Татарское кн. изд-во, 1982 г.- 280 с.

2. Амиров К.Ф. Казань: где эта улица, где этот дом? Справочник улиц города Казани.-Казань: Изд-во “Казань”, 1995 г

3. Багаутдинова Д.Б. Музей Габдуллы Тукая в Казани: Путеводитель.-Казань, Татарское кн. изд-во, 1989 г


4. Бикбулатов Р., Мустафин Р. Казань и её слободы.-Казань, изд-во “Заман”, 2001 г

5. Бикчәнтәев К. Солтан мәчете.-Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2004.-112 б.

6. Кузьмин В.В. Казань (путеводитель).-Казань, Татарское кн. изд-во, 1977 г.-

7. Татар энциклопедия сүзлеге.-Казан, Татар энциклопедиясе институты, 2002.

8. Якупов Х.Г. Рәсем-мәхәббәтем минем. Рәссам язмалары, фотолар, әсәрләренең фотокүчермәләре.-Казан: Татар. кит. нәшр., 2000




**Экскурсиянең маршрутының башы**



**Казан Кремле**



**Элеке Кремль урамы**



**Хәзерге Кремль урамы**




**Александров пассажы**



**Чернояров пассажы**



**Ушакова йорты**





**Казан дәүләт университеты**




**Бауман урамы**




**Кабан күле**




**Иске – Татар бистәсе**




**Иске – Татар бистәсенең мәчетләре**

**Укытучылар мәктәбе**





**Солтан мәчете**



**Мөхәммәдия мәдрәсәсе**

## МӘРҖӘНИ МӘЧЕТЕ

